| ГЛАВА БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БИЛӘР АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12. 2021 с. Билярск № 10

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 15 декабреннән 18 декабренә кадәр график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны тоту (юлларны кардан чистарту, юл читендәге үләннәрне чаптыру);
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (Комсомол ур., Украина ур., Совет ур., Киң ур.);

- җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (авария хәлендәге агачларны кисү һәм җыештыру, шартнамә буенча түләү);
- техниканы - тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- сүүткәргечне ремонтлау;
- эре габаритлы чүп-чар җыю (айга бер тапкыр)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Биләр авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр ав., Калинин ур., 3 й.; Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр ав., Ленин ур., 6 й.; Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы** **Г.Г.Хәбибуллин**

СОВЕТ БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының
Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын этаплап уздыру
ГРАФИГЫ**

| Тәртип саны | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 15.11.2021 | 9-00 | Биләр АМЙ | Халиков ур., Пролетар ур., Кыр ур. |
| 2 | 15.11.2021 | 11-00 | Биләр АМЙ | Биләр ур., Некрасов ур., Октябрь ур. |
| 3 | 15.11.2021 | 14-00 | Биләр АМЙ | Калинин ур, Ульянов ур, Урицкий ур. |
| 4 | 16.11.2021 | 9-00 | Биләр АМЙ | Бутлеров ур., Ленин ур., Ленин тык.ур. |
| 5 | 16.11.2021 | 11-00 | Биләр АМЙ | Бакча ур., Тауасты ур., Совет ур. |
| 6 | 16.11.2021 | 14-00 | Биләр АМЙ | Чапаев ур., Гагарин ур., Көнчыгыш ур. |
| 7 | 17.11.2021 | 9-00 | Биләр АМЙ | Мәктәп ур., Кызыл Армия ур., Куйбышев ур., Украинка ур. |
| 8 | 17.11.2021 | 11-00 | Биләр АМЙ | Ан. Серов ур., Киров ур., Нариманов ур, |
| 9 | 17.11.2021 | 14-00 | Биләр АМЙ | Краснобор ур., Комсомол ур., Ак.Арбузов ур., Яңавыл ур. |
| 10 | 18.11.2021 | 9-00 | Биләр АМЙ | Мәктәп тык. ур., Урманасты ур., Мартынов ур. |